КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 16 декабрь г.Казань № 1149

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесен оештыру турында» 2013 ел, 28 февраль, 136 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесен оештыру турында» 2013 ел, 28 февраль, 136 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 29 апрель, 293 нче; 2014 ел, 24 декабрь, 1020 нче; 2016 ел, 2 март, 128 нче; 2016 ел, 26 декабрь, 987 нче; 2017 ел, 8 сентябрь, 642 нче; 2017 ел, 30 октябрь, 820 нче; 2018 ел, 24 июль, 585 нче; 2019 ел, 22 гыйнвар, 30 нчы; 2019 ел, 29 март, 235 нче; 2019 ел, 19 июль, 606 нчы; 2019 ел, 21 сентябрь, 869 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 нче пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына:»;

8 нче пунктта «Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасының Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы» сүзләренә алыштырырга;

10 пунктта «Икътисад, финанс һәм дәүләт мөлкәте белән эш итү идарәсенә» сүзләрен «Мәгълүмат технологияләре, элемтә һәм мәгълүматны саклау идарәсенә» сүзләренә алыштырырга.

2. Бу карар 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин